ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/14

Хезмәт командировкаларына җибәргәндә гарантияләрне тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге 31/10 санлы Карары (Шәһәр Советының 2015 елның 17 декабрендәге 4/10 санлы Карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында, муниципаль органында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезнамәнең 17 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «а» һәм «б» пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«а) муниципаль хезмәтнең югары вазифаларын биләүче хезмәткәрләргә бер урынлы номерның бәясе буенча: Мәскәү һәм Санкт-Петребург шәһәрләре буенча – 5000 сумнан артык түгел, Россиянең башка шәһәрләре буенча – 3000 сумнан артык түгел;

б) башка муниципаль хезмәткәрләргә:

- бер урынлы номерның бәясе буенча: Мәскәү һәм Санкт-Петребург шәһәрләре буенча – 3000 сумнан артык түгел, Россиянең башка шәһәрләре буенча – 2500 сумнан артык түгел;

- ике урынлы номерда бер урынның бәясе буенча: Мәскәү һәм Санкт-Петребург шәһәрләре буенча – 1500 сумнан артык түгел, Россиянең башка шәһәрләре буенча – 1200 сумнан артык түгел.».

2. Торак урынны броньлау һәм наймга алу буенча чыгымнар командировкага җибәрелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә һәм муниципаль хезмәткәрләренә бер урынлы номер бәясе буенча тиешле документлар белән расланган фактдагы чыгымнар буенча кире кайтарыла: Мәскәү һәм Санкт-Петребург шәһәрләре буенча – 3000 сумнан артык түгел, Россиянең башка шәһәрләре буенча – 2500 сумнан артык түгел.

Даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән өстәмә чыгымнар (тәүлеклек акча) муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен, ял һәм бәйрәм көннәрен кертеп, шулай ук юлда булган көннәрне, шул исәптән юлдагы мәҗбүри тукталыш вакыты өчен түләнә: Мәскәү һәм Санкт-Петребург шәһәрләре буенча – 700 сум, Россиянең башка шәһәрләре буенча – 350 сум.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев